**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 июнь № 346

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 декабрь, 919 нчы; 2016 ел, 13 гыйнвар, 5 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 783 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан А.В.Песошинны чыгарырга;

эшче төркем составына Рөстәм Камил улы Нигъмәтуллинны – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын, эшче төркем җитәкчесен кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Зеленодольск моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2016 ел, 14 декабрь, 927 нче карары белән расланган Зеленодольск моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан А.В.Песошинны чыгарырга;

эшче төркем составына Рөстәм Камил улы Нигъмәтуллинны – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын, эшче төркем җитәкчесен кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\346.doc